Шәһәр күләмендә биология фәненнән татар телендә үткәрелә торган олимпиаданың мәктәп этабы биремнәре
2025-2026 нчы уку елы
8 нче сыйныф.

Эш вакыты –120 минут
Гомуми балл – 52

I Бүлек. Сезгә тест сораулары бирелә, шулар арасыннан бер дөрес җавапны сайлап алып, җаваплар матрицасына языгыз. (максимум 20 балл)

1. Үсемлекләрнең төп запас углеводы:
А) клетчатка Б) крахмал В) фруктоза Г) сахароза

2. Үсемлектә нинди тукымада тере күзәнәкләр булмый?
А) япма Б) төп В) механик Г) запас

3. Нинди үсемлек орлыгында май аз күләмдә?
А) киндер Б) җитен В) борчак Г) көнбагыш.

4. Тамыр нинди функцияне үти:
А) механик Б) суыргыч В) үткәргеч Г) барлык бу функцияләрне

5. Башлары губкасыман матдәдән торган сөякне ничек атыйлар?
А) нурлы Б) терсәк
В) күкрәк Г) бармак фалангалары

6. Үкчә сөяге кергән сөяк тибын әйтегез.
А) көпшәсыман Б) яссы
В) катнаш Г) губкасыман

7. Эчке мохит компоненты:
А) үт Б) лимфа
В) ашказаны асты согы Г) ашказаны стеналарын каплый торган лайла

8. Кайсы орган ашкайнату функциясен генә түгел, гумораль функцияне дә үти?
А) бавыр Б) ашказаны асты бизе
В) аппендикс Г) ашказаны

9. Кечкенә генә тырналган урында тиредә ачык төстәге сыеклык тамчылары калкып чыга. Бу нинди сыеклык?
А) кан Б) лимфа
В) күзәнәкара (тукыма) сыеклык Г) кан плазмасы

10. Хордалыларның нерв системасы формалаша:
А) яралгының арка ягындагы энтодермадан
Б) яралгының арка ягындагы эктодермадан
В) яралгының корсак ягындагы энтодермадан
Г) яралгының корсак ягындагы эктодермадан

11. Имезүчеләрнең ароморфозларына түбәндәгеләрне кертергә кирәк:
А) эчке скелеты булу
Б) үскән мозжечок
В) нерв трубкасы барлыкка килү
Г) кан әйләнешенең ике түгәрәге булу һәм җылы канлылык

12. Сулыклардан су эчкәндә нәрсә йоктырырга мөмкин?
А) үгез чылбыры финнары
Б) бизгәк чире
В) эхинококк
Г) бавыр имгече

13. XX гасырның иң күренекле зоологик ачышларының берсе булып тора:
А) ике сулышлы балык Б) чук канатлы балык
В) кимерчәкле балык Г) панцирлы балык

14. Канның икенче төркеме нәрсә белән аерыла?
А) α һәм β агглютининнар
Б) β агглютинин һәм А агглютиногеннары
В) А Һәм В агглютиногеннарын
Г) α агглютининын һәм В агглютиногенын

15. Фотосинтез процессында үсемлекләр нинди газ куллана?
А) углекислый газ Б) газ катнашмасы
В) азот Г)көндез кислород, төнлә углекислый газ

16. Монда нинди үсемлекнең формуласы күрсәтелгән: Ч5 В5 Т п П5?
А) алмагачлар Б) лилияләр
В) магнолияләр Г) борчак

17. Нинди типтагы хайваннарда беренче тапкыр мезодерма барлыкка килә?
А) эчәккуышлылар Б) божралы суалчаннар
Б) яссы суалчаннар Г)моллюсклар

18. Өч капкачлы клапан кайда урнашкан?
А) сул йөрәк алды белән карынчык арасында
Б) уң йөрәк алды белән карынчык арасында
В) уң карынчык белән үпкә артериясе арасында
Г) сул карынчык белән аорта арасында

19. Кайсы отряд вәкиленең түбәндәге теш формуласы бар:
I 0/3 C 0/1 PM 3/3 M 3/3?
А) кимерүчеләр Б)Партояклылар
В) куянсыманнар Г) бөҗәк ашаучылар

20. Нерв системасы нинди яралгы яфрагыннан формалаша?
А) эктодерма Б)мезодерма В) энтодерма Г) бластодерма

Җавапларыгызны бланкларга күчереп язарга онытмагыз

II Бүлек. Төшереп калдырылган сүзләрне языгыз: (максимум 10 балл)
1. Мүксыманнарның тормыш циклында ..... буын өстенлек итә.
2. Хордалы хайваннарның нерв көпшәсе куышлыгы..... дип атала
3 …….....….. - ул төсе булмаган, ләкин төше булган кан элементлары.
4. Канның куеру процессы бозылу белән бәйле нәселдән килгән авыру..... дип атала
5. ДНКДА азотлы нигезләрнең дүрт төре очрый: аденин, гуанин, тимин һәм.....

III Бүлек. Сезгә 4 вариант арасыннан, бер дөрес җавап белән, тест биремнәре тәкъдим ителә. (максимум 9 балл)

1. Түбән төзелешләрнең күбесе циста барлыкка китерергә мөмкин. Ни өчен?
1) актив хәрәкәт итәргә
2) үрчергә
3) уңайсыз шартлардан сакланырга
4) тукланырга
5) таралырга

А) бары тик 1, 2
Б) бары тик 1, 5
В) бары тик 2, 3
Г) бары тик 3, 5
Д) 2, 3, 4.

2. Санап үтелгән авырулардан кайсыларын вируслар китереп чыгара?
1) корь
2) ящур
3) столбняк
4) котыру
5) себер түләмәсе

А) 1, 2, 3
Б) 1, 2, 4
В) 1, 3, 5
Г) 2, 3, 4
Д) 2, 4, 5

3. Яфраклар картайган саен:
1) хлорофиллар таркала
2) каротиноидлар туплана
3) кальций оксалаты кристаллары таркала
4) сулау интенсивлыгы арта
5) фотосинтезның интенсивлыгы кими

А) 1, 2, 3
Б) 1, 2, 5
В) 1, 3, 4
Г) 1, 3, 5
Д) 2, 3, 4

IV бүлек.

1. Сезгә тәңгәллекне билгеләүне таләп итә торган тест биремнәре тәкъдим ителә. (максимум 13 балл)

Кошларның алты төрле отряды вәкилләренең аскы очлыкларын карагыз һәм аларны отрядлар белән чагыштырыгыз.



1)чыпчыксыманнар
2)тавыксыманнар
3)тукрансыманнар
4)казуарсыманнар
5)тәвәсыманнар
6)кивисыманнар

2. Рәсемдә тавык йомыркасының төзелеше схемасы күрсәтелгән. Шартлы тамгаларны (1-7) йомырка структураларының исемнәре (А–З) белән чагыштырыгыз (структура исемнәре артыгы белән бирелгән!):

А) аксым
Б) йомырка сарысы
В) кабык
Г) канат (халаза)
Д) яралгы дисклары
Е) кабык өсте тышчасы
Ж) кабык асты тышчасы
З) һава камерасы